
# Тукай - халык баласы, аны халык устергән.





# Габдулла Тукай
# (1886 - 1913)


И туган тел! Синдә булган
Иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм
Әткәм-әнкәмне, ходам!
Габдулла Тукай
Г.КАМАЛ
ФАТИХ ӘМИРХАН
ВИДЫ
ГОРОДА
КАЗАНИ
1890
Кол Гали
Кыйссаи

# Шигъри табышмак:


- Җәй көне. Эссе һава мин суда койнам, йөзәм;
  Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм.

- Әйт әле, Күбәләк, сөйләшик бергәләп:
  Бу кадәр күп очып армыйсың син ничек?

- Күптән түгел безнең тәрәзә капкачын
  Оя итте минем сөйгән Карлыгачым.

- - Әйдәле, Акбай! өйрән син, арт аягың берлә тор;
  Аума, аума! туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!

**“Исемдә калганнар” автобиографик хикәясенең беренче бите.**



مقدمه.

بو « ایسمده قالغانلار » نی یازوومه باشلیچه سبب بر نیچه ناشرلرنڭ میندن ترجمهٔ حالمنی یازوب بیررگه اوتنولری بولدی.

مین آلارغه توغانمدن آلوب، حاضرگی بهشمه قدرگی ترجمهٔ حالمنی قصقهغنه رهوشده یازوب بیرو نیتی ایله قولمه قلم آلغان ایدم، ئهلله نیچك سوز اوزونغه کیتدی.

مینم عمرم (اوقوچیلار کوررلر) شافتی یهمسز، شافتی قارانغی، شونڭ بلهن برگه قزقغنه اوتکان بولغانغه، یازا باشلاغاچ ایسمده قالغانلارنڭ همهسن یازاسم کیلدی.

شونلقدن، اورالسکیگه کیلوب جیتکانمه قدر کیچردکم حاللر ایل، آندن صوڭ حاضر شوشی سطرلارنی یازوب اوطرغان وقتمه قدرگی باشمه کیلگانلارنی ایکیسن ایکی رساله ایتوب چغاررغه معقول کورلدی.

ع. توقای.

۲۹ نچی سینتهبر. ۱۹۰۹ نچی یل.

Габдулла Тукай 1886 елның 26 апрелендә Казан губернасы Мәңгәр волосте  Кушлавыч авылында Мөхәммәтгариф исемле мулла гаиләсендә дөньяга килә.



Әтисе Мөхәммәтгариф исемле Кушлавыч авылында мулла булып торган.
Әнисе Өчиле авылы Зиннәтулла хәзрәтнең Мәмдүдә исемле кызы.





- **Әти - әни назы һәм иркәләве озакка сузылмаган.**
- **1886 елның 29 августында әтисе үлә. Әнисе аны Шәрифә исемле карчыкка вакытлыча асрарга калдырып, үзе Сасна исемле авылның мулласына кияүгә чыккан.**
- **1890 елның 18 гыйнварында әнисе вафат булган. Шулай итеп Габдулла дүрт яше дә тулмаган килеш ятим, яклаучысыз, терәксез калган.**


Баштан Габдулла Зиннәтулла бабасының
зур гаиләсе белән Өчиле авылында яши.
“Исемдә калганнар” дигән истәлегендә Тукай болай яза:
“ Үги әбинең алты күгәрченнәре эчендә мин бер чәүкә булганга,
мине еласам юатучы, иркәләним дисәм, сөюче, ашыйсым, эчәсем
килсә, кызганучы бер дә булмаган, мине эткәннәр дә төрткәннәр...”





Зиннәтулла бабасы өендә яшәү Габдуллага рәхәт булмый. Монда ятимне бары Сажидә апасы яраткан.


Казан малайны шаулап каршы алган. Ямщик Казанга килеп җиткәч, Печән базарында: “ Асраугa бала бирәм, кем ала?”- дип кычкырып йөргәндә, халык арасыннан бер кеше чыгып малайны “уллыкка” алган.




Казан шәһәрендә һөнәрчеләр – Мәхәммәтгали абзый белән Газизә апа “артык” баланы үз гаиләләренә сыендыра. Нәни Габдулла бу мәрхәмәтле кешеләрне беркайчан да онытмаячак.




Бердәнбер бабасы Зиннәтулла Габдулланы Өчиле авылына үз йортына алган.






Казаннан соң Габдулла Кырлай авылында яшәгән. 1892 елның җәендә аны Сәгъди абзый гаиләсе уллыкка алган.

Кырлай малайлары нәни Габдуллага бик гаҗәпләнеп карап торалар.



“Бездә катык, сөт, ипи күп, теләгәнчә ашарсың,” - дигән Сәгъди абзый малайны Кырлайга алып кайтканда.




Кырлайда Сәгъди абзый йорты. Тукай монда 1892 елның җәеннән 1894 елның көзенә кадәр яши.



Кырлайда Фәтхерахман хәзрәт йорты.Нәни Габдулла шушы йортта абыстайдан сабак ала башлый.





**Кырлай авылы табигате һәм Сәгъди абзый гаиләсендә алган тәрбия шагыйрь Тукайның шигырь-әкиятләренә тәэсир иткән.**



**Шүрәле.**
**Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл - Кырлай диләр;**
**Җырлаганда көй өчен “тавыклары җырлай” диләр.**
**Гәрчә анда тумасам да, мин бераз торган идем;**
**Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем.**
**Ул авылның,-һич онытмыйм,-һәр ягы урман иде;**
**Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде.**
**Зурмы? – дисәң, зур түгелдер, бу авыл бик кечкенә;**
**Халкының эчкән суы бик кечкенә инеш кенә.**




**1895 елда Габдулла Җаекка, Уральск шәһәренә әтисе ягыннан туган Газизә апасы һәм аның ире Галиәсгар җизнәсе янына күчеп килә.**



**Уральск шәһәрендә нәни Апуш акыллы, тәртипле шәкерт Габдулла Тукаев булып танылган.**

Нибары 27 елга җыелган кыска гомер. Кыскалыгын кыска да бит, ләкин шул  ук вакыт аралагында бөтен бер олуг татар дөньясы аны үзенең мәңгелек углы итеп таныган.



- **Эшләде:**

**58 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең**
**I квалификацион категорияле**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Арсентьева Вера Ивановна**